Илалетдинова Миңлегаян дәфтәреннән

Чыгар идем олы юлга, олы юл нур белән тулган,
Әлхәмдүлилляаһи шөкер - Мөхәммәт өммәте булган.

Гамәлләрне укыгачтин бәндәләрнең һушы китәр,
Гөнаһлы бәндәләргә зәбанилар килеп җитәр.

Раббем Алла, Раббем Алла, җаннарымны каты алма,
Җаннарымны каты алсаң, ни җаваплар бирим анда.

Иляһым, Син минем Раббем, безнең хәлләр Сиңа мәгълум,
Сигез җәннәт сараеннан куймасана безне мәхрүм.

Чәчәк вакты әле дими, авыр үлем хәле дими,
Җаннарыннан артык булган яры кала моның дими.

Кабер атлы мәхкәм сарай, ишеге юк ачып булмый,
Кабердәге әрвахларның хәлен сорап-белеп булмый.

Ходай йөземне ак кыйлсын каберләрдән кубарганда,
Хисабларым җиңел булсын хозурларына барганда.

И дускаем, димәдемме, үләсеңне белмәдеңме,
Чарасыз тар каберләргә керәсеңне белмәдеңме.

Укыйм микән, җитәр микән, бу хәсрәтем бетәр микән,
Җылый-җылый дога кыйлсам, бу эчләрем бушар микән.

www.tatars.com

Түбән Мактама,
Әлмәт районы,
Татарстан
Ләйсирә Илалетдинова
язды

## Якты дөньяны күреп туймадым

Әҗәл ширбәтен бер көн эчәрмен,
Якты дөньядан бер көн кичәрмен.

Әҗәлем җитәр, тыннарым бетәр,
Ясин укырга вакытлар җитәр.

Укый алмамын, бетәр сулышым,
Артымнан калсын дога кылучым.

Газраил килер, җанымны алыр,
Кызыл йөзләрем саргаеп калыр.

Якты дөньяны ташлап китәрмен,
Караңгы гүрдә ни хәл итәрмен?

Караңгы гүрдә калыр бу башым,
Фәрештәләрме булыр юлдашым?

Мөшкел хәл икән, җанны бирүе,
Авыр хәл икән гүргә керүе.

Зифа буемны үлчәп алырлар,
Караңгы гүргә илтеп салырлар.

Зәгыйфь тәнемне каты тотмагыз,
Кире кайталмам, ашыктырмагыз.

Ерак җирләрдән дуслар килгәннәр,
Карап калсыннар якын күргәннәр.

Йорттан чыкканда ашыгып чыкмагыз,
Бик елашмагыз, зинһар, чыдагыз.

Тордым дөньяда бераз вакытлар,
Салкын туфрактан безгә ястыклар.

Бу ят җирләргә кемнәр китергән?
Безгә йортларны кемнәр җиткергән?

Иптәш калмаган, түшәк җәймәгән...

[illegible] Шамсетдинова архивыннан

www.tatars.com

## Бу ни гаҗәп, бу ни хикмәт

Тугыз ай күтәреп йөрдем,
Тугач ак сөтемне бирдем,
Бу ни гаҗәп, бу ни хикмәт,
Баламнан катылык күрдем.

Үләр хәлләремә җиткәч,
Хәлемне сорамый балам,
Бала күңеле каты икән,
Бәхилләп үлми бит анаң.

Авырсам да ышанмадың,
Хәлемне һич сорамадың,
Авыр булса да хәлләрем —
Тузан чаклы кызганмадың.

Эй, бәбкәем, газиз балам,
Мин бит сине тапкан анаң,
Туган көнеңдә шатландым,
Хөрмәт итәр диеп, балам.

Әй, газиз бәгърем, парәм,
Ике күземдәге карам,
Мин үлеп гүрләргә кергәч,
Табылмас бит газиз анаң.

Сезләрне карап үстергән,
Начар булса да - анагыз,
Хөрмәт күрәсегез килер,
Сезнең дә булыр балагыз.

Тавыш оригиналы
Айгуль Шамсетдинова
архивыннан

www.tatars.com

Картлык нишләтә?

Явыз бу картлык, шәфәгать юк анда,
Кара җирләргә илтеп тә кертә.

Бу картлык шул ягы белән ярый -
Бөтенәйсен дә бер тигез карый.

Булсын ул бик бай, булсын ул түрә,
Фәкыйрь булса да бер тигез күрә.

Алтмыштан узгач картлык башлана,
Дөнья кирәкми, эшләр ташлана.

Җитмешкә кадәр ул барыбер эшли,
Бу картлыкка ул әле бирешми.

Җитмеш биштә әз эшли башлый,
Авыр эшләрне бөтенләй ташлый.

Сиксәнгә җиткәч эшләми башлый,
Барлык эшләрне кулыннан ташлый

Ул чыга юлга өч аяк белән,
Экрен генә бара да бара,
Алай да үзе байтак юл ала.

Сиксән бишкә җиткәч, бераз туктала,
Бераз ял иткәч, бераз юл ала.

Бара-бара да юлдан адаша,
Туксан яшенә җитеп маташа.

Туксанга җиткәч, таягын ташлый,
Караватыннан төшми дә башлый.

Ята да тора, бераз утыра,
Утыргач арый, яту ягын ~~тизрәк~~ карый.

Картлыкның соңгы чарасы –
Сиксән белән туксан арасы.

www.tatars.com

Балаларым чыкмый истән

Йосыф китап көе белән мин көйлимен,
Иртә торып чәчләремне мин тарыймын,
Биек тауга йөгереп менеп мин карыймын
Күренмәсме газиз балаларым диеп.

Һич туктаусыз яшь түгәдер ике күзем,
Сары яфрак кебек булды бәнем йөзем,
Сезнең берлән бер авылда булсам үзем,
Хәсрәтемнең бик күбесе бетәр иде.

Кичләр булса карыймын мин ки айларга
Балаларым йөри икән дип кайларда,
Алар да дим карый микән бу айларга,
Аларн[ы]уйлап хәлсез булып керәм инде.

Балаларым өчен өз[е]лә эчкәйләрем,
Кичен ятсам болганадыр төшкәйләрем,
Уянам да ялынамын мин Тәкъдиргә,
Кавыштыргыл балаларым белән, димен.

Күтәрелми күңелләрем минем һичтә,
Ачы хәсрәт уты яна минем эчтә,
Сердәшем юк, киңәшчем юк - ялгыз башым,
Бу башларым тагын ниләр күрер инде.

Ничә көннәр утырадыр ялгыз башым,
Ямансулап җирсеп үтә бар вакытым,
Бәбкәсеннән аерылган казлар кебек
Көнем-төнем ямансулап үтә инде.

Кайгы-хәсрәт күргәннәрнең бәгъре яна,
Кайгы -хәсрәт күрмәгәннәр уенга санар,
Кемнең итәгенә төшсә аныкы янар,
Фирак уты һич ялкынсыз янар инде.

www.tatars.com

Оригинала Юсуф Мустафиновна
Архивында